АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ
ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ
СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ

**РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА** **ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 30.05.2019 № ПР-134-3

г. Казань

**Татарстан Республикасы территориясендә почта элемтәсе бүлекчәләренең халыкка хезмәт күрсәтү буенча эше турында**

"Россия почтасы" ФГУП филиалы – "Татарстан почтасы" УФПС операция идарәсе буенча директор урынбасары Л.Ф.Бәдертдинованың Татарстан Республикасы территориясендә почта элемтәсе бүлекчәләренең халыкка хезмәт күрсәтү буенча эше турындагы мәгълүматын тыңлап һәм тикшереп, "Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы" (алга таба – Совет) Ассоциациясе президиумы **карар бирде:**

1. "Россия почтасы" ФГУП филиалы – "Татарстан почтасы" УФПС операция идарәсе буенча директор урынбасары Л.Ф.Бәдертдинованың мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләренә билгеләнгән тәртиптә түбәндәге мәсьәләләрне карарга тәкъдим итәргә:

- "Россия почтасы" ФГУП федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы – "Татарстан почтасы" УФПСнә Федераль почта элемтәсе идарәсе аерымланган структур бүлекчәләре почта элемтәсе бүлекчәләре янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү буенча ярдәм итү;

- авыл җирлекләрендә почта элемтәсе бүлекчәләрендә вакантлы вазыйфаларга кадрлар сайлап алу буенча үзара хезмәттәшлек күрсәтү.

3. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына Татарстан Республикасы территориясендә почта элемтәсе

3. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына Татарстан Республикасы территориясендә почта элемтәсе бүлекчәләре эшенә булышлыкның өстәмә чаралары турында тәкъдимнәр эшләргә тәкъдим итәргә.

4. “Россия почтасы” ФГУП филиалы – “Татарстан почтасы” УФПСнә билгеләнгән тәртиптә түбәндәге мәсьәләләрне карарга тәкъдим итәргә:

- “Россия почтасы” ФГУП филиалы – “Татарстан почтасы” УФПС хезмәткәрләренә (башлыклар, почтальоннар) акчалата түләүне арттыру;

5. Әлеге карарны үтәүгә контрольне Советның башкарма секретаре А.Г.Барышевка йөкләргә.

**Рәис** **Ә.С. Гобәйдуллин**